ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**17.01.2022**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 42**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районының Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең, бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 24 апрелендәге 976 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләүне тәртипкә салу максатларында һәм «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 7 декабрендәге 1189 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карарының 4 пунктына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 24 апрелендәге 976 номерлы «Зеленодольск муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» гы карарына (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 20.08.2020 ел, №1557 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта

өченче абзацта «компенсация түләүләрен» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче абзацта «һәм компенсация түләүләрен » сүзен төшереп калдырырга;

5 пунктта

1 пунктчада «50» санын «8»санына алмаштырырга;

3 пунктчада «айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендә премияне исәпкә алып, ике айлык тариф ставкасы» сүзләрен «бер айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктчада

икенче абзацта «25» санын «5»санына алмаштырырга;

өченче абзацта «10» санын «2»санына алмаштырырга;

6 пунктчада

өченче абзацта «35» санын «7»санына алмаштырырга;

бишенче абзацта «50» санын «10»санына алмаштырырга;

8 пункттa

беренче абзацта «(компенсация түләүләрен исәпкә алып)» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктчада «тугыз айлык ставканың» сүзләрен «бер бөтен сигез айлык тариф ставкасының» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктчада «өч айлык тариф ставкалары» сүзләрен «бер айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктчада «айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендә премияне исәпкә алып, ике айлык тариф ставкасы» сүзләрен «бер айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И. Р. Ганиев